**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2021елның 28 сентябре 2812 номер

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә 2021 елга капиталь ремонт программасына кертелгән капиталь ремонт тәмамланган күпфатирлы йортларны эксплуатациягә алу комиссиясен төзү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм күпфатирлы йортка капиталь ремонт тәмамланган йортның сыйфатын тикшерүне гамәлгә ашыру һәм аны эксплуатациягә тапшыру максатларында **карар бирәм:**

1. 2021 елга капиталь ремонт программасына кертелгән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә капиталь ремонт тәмамланган күпфатирлы йортларны файдалануга кабул итү комиссиясе составын расларга (кушымта).
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.П. Шитовка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**

Лаеш муниципаль районының
Башкарма комитетының
________елның __ номерлы
карарына кушымта

2021 елга капиталь ремонт программасына кертелгән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә капиталь ремонт тәмамланган күпфатирлы йортларны файдалануга кабул итү комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; Комиссия рәисе | - | А.А. Новиков |
| Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары | - | И.П. Шитов |
| Лаеш муниципаль районының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге баш белгече, комиссия секретаре | - | Э.К. Афанасьева |
| Комиссия әгъзалары - вәкилләр | | |
| | | |
| «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы фонды» НО генераль директоры (килешү буенча) | - | А.А. Әбүзәрев |
| Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының торак-коммуналь хуҗалык программаларын эксплуатацияләү һәм гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) | - | А.А. Галләмов |
| Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең үзәк инспектор бүлеге башлыгы (килешү буенча) | - | Е.Н. Арефьева |
| «Төзелеш компанияләре конссорциумы» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) | - | Д.В. Попов |
| «ТАУР төзелеш компаниясе» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) | - | Р.Н. Гайфуллин |
| "Дружба" ТСЖ рәисе (килешү буенча) | - | А.Н. Сучков |
| «Габишево» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) | - | Э.Р. Таҗиева |
| "Экономстрой" директоры (килешү буенча) | - | Р.Р. Хәйруллин |
| «УК «Нармонка» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) | - | Р.Н. Гарипова |
| Йорт буенча өлкән (килешү буенча) | | |